| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА<br>ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ САБИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

28.09.2022 — № 923-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 сентябрендәге 1126-п номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Саба районы Прокуратурасының 2022 елның 31 мартындагы гамәлдәге норматив хокукый актларны анализлау зарурлыгы турындагы мәгълүматын үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “ Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2021 елның 29 сентябрендәге 1126-п номерлы карары белән расланган, җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1** Административ регламентның 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.2. Хезмәттән файдаланучылар – физик затлар – әгәр мондый гражданнар Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлеге бирү көненә кадәр биш ел даими яшәп торалар һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торсалар, язылышкан яки язылышмаган, ләкин бергә яшәүче ата-ана (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) яки ата-ананың берсе (уллыкка алучы, опекун, попечитель) (алга таба – ата-ана), шулай ук җир кишәрлеген милеккә тапшыру турында гариза бирү вакытына унсигез яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк бала, шул исәптән үги малайлар, үги кызлар, уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган затлар (аларга

карата опека һәм попечительлек вакыты чикләнмәгән яки балигъ булу яшенә җиткәнче гамәлгә ашырыла) булган күпбалалы гаилә әгъзалары (алга таба – гариза бирүче).

Шул ук вакытта күпбалалы гаилә составына, кимендә өч уртак баласы булган очракта, язылышмаган ата-ана да керә. Чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясындагы 3 пунктында каралган нигезләрдә җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү (тапшыру) хокукын гамәлгә ашырган гражданнар күпбалалы гаилә составына керми.

Әгәр дә атасы яисә анасы яки бердәнбер ата-ана җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәсә, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү турындагы таләп каралган пунктка туры килә дип санала.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба - мөрәҗәгать итүче вәкиле) тапшырырга мөмкин.»;

**1.2** Административ регламентның 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

9) җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән көнгә кадәрге биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта).

**1.3** Административ регламентның 2.6.1 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

фамилия-исем төркеме, туган вакыты, җенесе һәм аерым шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС) тәңгәллеген тикшерү – Россия Федерациясе Пенсия фонды;

**1.4** Административ регламентның 2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«9) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗ буларак исәптә торуын раслый торган документ-авыл (шәһәр) җирлегенең Башкарма комитетлары;

**1.5** Административ регламентның 2.8.2 пунктының 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптән төшерү;»

**1.6** Административ регламентның 2.8.2 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) җир кишәрлеген сайлау процедурасында гражданнарның өч тапкыр җир кишәрлеген сайлаудан баш тартуы, яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасына гражданнарның өч тапкыр килмәве, яисә гражданнарның җир кишәрлеген сайлау

процедурасында җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту һәм аларның җир кишәрлеген сайлау процедурасына килмәү очракларының гомуми саны өчкә тигез;».

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов